**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4861**
**25.09.2019**

Гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булып торган гражданга җир участогын түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 267-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның 2011 елның 30 мартындагы 1576 нчы карары белән расланган Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында нигезнамә нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2015 елның 31 июлендәге 4350 нче карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 22 июнендәге 3184 нче, 2018 елның 29 ноябрендәге 7118 нче, 2019 елның 10 июлендәге 3548 нче карарлары редакциясендә) рсланган гражданнарның коммерцияле булмаган бакчачылык, яшелчәчелек, дача берләшмәсе әгъзасы булып торган гражданга җир участогын түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 1.1. пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә: «137-ФЗ санлы Федераль законның 3 маддәсенең 2.7 пункты нигезендә, муниципаль хезмәт 2022 елның 1 мартына кадәр күрсәтелә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә, имзаланган көннән башлап җиде көн срокта әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» челтәрендә ТР хокукый мәгълүматының рәсми порталында (htpp://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин